**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Күәм авыл җирлеге Әйшияз торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“8” ноябрь 2025 ел.

№ 2

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлегенең Әйшияз торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Әйшияз авылы территориясендә 2026 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлегенең Әйшияз торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 нче төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

-Торак пункт территориясен төзекләндерү (балалар өчен уен мәйданчыгы урнаштыру, төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле Автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Урамнарны кардан чистарту, эш һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм подстанция мәйданчыкларын, бүлү пунктларын, электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктырту өчен яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру, хезмәтләр өчен түләү);

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлегенең Әйшияз авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Күәм авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Әйшияз авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күәм авыл җирлеге башлыгы Сәмигуллин Л.Ә.